ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

__30.04.2019 г._____ с. Муслюмово №___184____

**2019 нчы елда гомуми белем бирү мәктәпләренең 10 нчы сыйныф укучылары һәм ДАҺББУ "Сарман аграр көллияте"нең 1 нче филиалының чыгарылыш алды курсы студентлары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча бишкөнлек җыенны оештыру һәм үткәрү буенча**

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында" 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү йөзеннән, районның мәгариф учреждениеләре укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре дәресләрендә алынган хәрби белемнәрне һәм күнекмәләрен практик рәвештә ныгыту максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Мөслим гимназиясе (43 кеше) һәм Мөслим авылы "Сарман аграр көллияте" дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең 1 нче филиалы (36 кеше) базасында гомуми белем бирү мәктәпләренең 10 нчы сыйныф укучылары һәм ДАҺББУ "Сарман аграр көллияте"нең 1 нче филиалының чыгарылыш алды курсы студентлары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча бишкөнлек җыеннары үткәрү пунктлары булдыру.

2.Бишкөнлек җыеннарны 2019 елның 27 маеннан 31 маена кадәр үткәрергә.

3. "2019 нчы елда гомуми белем бирү мәктәпләренең 10 нчы сыйныф укучылары һәм ДАҺББУ "Сарман аграр көллияте"нең 1 нче филиалының чыгарылыш алды курсы студентлары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча бишкөнлек җыенны оештыру һәм үткәрү өчен эш планын расларга. (1нче кушымта)

4.

- Бишкөнлек җыенның җитәкчесе итеп Татарстан Республикасы ДОСААФ региональ иҗтимагый - дәүләт берләшмәсе Мөслим җирле оешмасы рәисе Бадретдинов Н.Ә.ны билгеләргә (килешү буенча);

- Бишкөнлек җыенның үткәрү пунктлары җитәкчеләре итеп Мирзаянов А.Ф.ны (“Мөслим гимназиясе” директоры) һәм Шәймөхәммәтова А.Р.ны

(Мөслим авылы ДАҺББУ "Сарман аграр көллияте"нең 1 нче филиалы директоры) (килешү буенча) билгеләргә

5. "Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» начальнигы Демидовка Р.Т. һәм ДАҺББУ "Сарман аграр көллияте"нең 1 нче филиалы директоры Шәймөхәммәтова А.Р. ка тәкъдим итәргә:

- ТИН дәресләрен укытучы укытучыларының, гомуми белем бирү мәктәпләренең 10 нчы сыйныф укучыларының һәм чыгарылыш алды курсы студентларын бишкөнлек җыенда катнаштыруны оештырырга, уку программаларының үтәлешен, уку җыеннарын билгеләнгән вакытта әзерләү һәм үткәрү буенча план чараларын тәэмин итәргә;

- Җыеннарның үткәрү пункты администрациясе составын төзергә, оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә;

- Җыеннарны үткәрү чорына дежур машинаны бүлеп бирергә.

6. Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы (Яббаровка И. Р.) спорт ярышларын, мәдәни ял чараларын оештыруда, үткәрүдә һәм укыту планы нигезендә физик әзерлек нормативларын тапшыруда булышлык күрсәтергә.

7. Финанс-бюджет палатасы рәисенә (Бубекова Н.Ә.) расланган сметага ярашлы рәвештә, транспорт чыгымнары, туклану һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүгә акча бүлеп бирү.

8. Тәкъдим итү:

8.1. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Сарман һәм Мөслим муниципаль районнары буенча бүлеге начальнигы (Гасанова Д. Г.) запастагы офицерларны һәм хәрби комиссариат хезмәткәрләрен уку җыеннарын үткәрүгә җәлеп итәргә, уку җыеннары планы нигезендә чаралар үтәүне оештырырга, ату вакытында куркынычсызлык чараларын тәэмин итәргә.

8.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим муниципаль районы буенча бүлеге начальнигы (Гатауллинга Р.Р.) уку җыеннары үткәрү урыннарында җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлык тәэмин итәргә, автотранспортта җыюда катнашучыларны куркынычсыз йөртергә, автоматтан ату вакытында куркынычсызлык чараларын тәэмин итәргә.

8.3. «Мөслим район үзәк хастаханәсе»нең баш табибы (Морзаханов Р.А.) ату көнендә «ашыгыч медицина ярдәме» бригадасының бишкөнлек җыенн пунктларында медицина хезмәтен тәэмин итәргә.

8.4. Мөслим гимназиясе директорына (Мирзаянов А.Ф.) бишкөнлек җыеннарны үткәрү пунктлары территорияләрендә һәм азык-төлек блогында санитар таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәргә.

9. МУО «Хуҗалык белән тәэмин итү» оешмасы җитәкчесенә (Шакиров А.Г.) укучыларны уку җыемнары һәм ату урыннарына алып баруны оештырырга.

10. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» башлыгы (Демидовка Р.Т.) һәм ДАҺББУ "Сарман аграр көллияте"нең 1 нче филиалы директорына (Шәймөхәммәтовка А. Р.) 2019 елның 16 июненә кадәр бишкөнлек җыеннары нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирергә.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» начальнигы Демидов Р.Т.ка йөкләргә.

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Х. Ахметов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
“___” _________ 2019 елның
№________ карарына кушымта

**2019 нчы елда гомуми белем бирү мәктәпләренең 10 нчы сыйныф укучылары һәм ДАҺББУ "Сарман аграр көллияте"нең 1 нче филиалының чыгарылыш алды курсы студентлары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча бишкөнлек җыенны оештыру һәм үткәрү өчен эш планы**

| № | Чараның исеме | Үтәлеш вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| | **Мәгариф идарәсе буенча** | | |
| 1 | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Сарман һәм Мөслим муниципаль районнары буенча идарәсе начальнигы катнашында урта гомуми белем бирү мәктәпләре җитәкчеләре, «Тормыш иминлеге нигезләре» укытучыларының киңәшмәсе | 17.05 | Мәгариф идарәсе |
| 2 | Уку-укыту матди базасын, спорт мәйданчыкларын һәм залларны әзерләү планын раслау. | 19.04 | Мәгариф идарәсе |
| 3 | Бишкөнлекне уздыру турында Башкарма комитет карары проектын эшләү | 16.04. кадәр | Мәгариф идарәсе ББУ җитәкчеләре |
| 4 | Бишкөнлекнең дәресләр расписаниесен карау һәм көн тәртибен раслау. | 17.04 кадәр | Мәгариф идарәсе |
| 5 | Уку планын һәм спорт-массакүләм эш планын раслау. | 17.04 кадәр | Мәгариф идарәсе |
| 6 | Бишкөнлек җыенны үткәрү буенча мәгариф идарәсе боерыгын әзерләү. | 18.04 кадәр | Мәгариф идарәсе |
| | **Белем бирү учреждениеләре буенча** | | |
| 1 | Бишкөнлек җыенны үткәрү вакыты һәм урыны турында, чарага җәлеп ителә торган укучылар, укытучылар һәм персонал санын билгеләгәндә, белем бирү учреждениесе җитәкчесенең боерыгын әзерләү. | 24.05 кадәр | Белем бирү учреждениесе җитәкчеләре |
| 2 | Җыенны үткәрү урыннарын кирәкле инвентарь һәм җиһазлар белән тәэмин итү. | 20.05 кадәр | Белем бирү учреждениесе җитәкчеләре |
| 3 | Укучылар белән дәресләр үткәрү өчен | 20.05 | ТИН укытучылары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | методик эшләнмәләр, планшетлар, уку карталары, линейкалар, компаслар һ.б. әзерләү. | кадәр | |
| 4 | Җыен өчен әзерлек материаллар ясау, күрсәтмә агитация үткәрү (бланклар, стенгазета һ.б.) | 20.05 кадәр | ТИН укытучылары |
| 5 | Укучыларны әзерләү:<br>- көн тәртибен өйрәнү, тәүлеклек киемдәге затларның бурычлары белән танышу,<br>- җыемнар вакытында укучыларның шәхси гигиена, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре,<br>- ату һәм дәресләр үткәргәндә куркынычсызлык чаралары турында инструкция,<br>- укучыларның саф смотрын үткәрү һәм хәрби типтагы бүлек формалаштыру | 28.05 кадәр | ТИН укытучылары |
| | **Хәрби комиссариат, башка оешмалар һәм учреждениеләр буенча** | | |
| 1 | Укучыларны тукландыру, транспорт чыгымнары һәм ату үткәрү өчен акча бүлеп бирү | 20.05 кадәр | Белем бирү учреждениеләре |
| 2 | Укучыларны чаралар үткәрү урыннарына йөртү өчен гаризалар буенча автобуслар белән тәэмин итү (ярышлар, ату) | 27.05-31.05 | МУО «Хуҗалык белән тәэмин итү» оешмасы җитәкчесе (килешү буенча)<br>Белем бирү учреждениесе җитәкчеләре |
| 3 | Тактик дәресләр һәм ату үткәрү урынында медицина хезмәте күрсәтүне һәм санитар контрольне тәэмин итү. | 27.05-31.05 | ДАССУ «Мөслим үзәк район хастаханәсе» (килешү буенча) |
| 4 | Мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын оештыру | 27.05-31.05 | Мәгариф идарәсе<br>Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| | Махсус һәм физик әзерлек буенча нормативларны үтәүне оештыру | 27.05-31.05 | Мәгариф идарәсе |
| 5 | Ату буенча нормативлар үтәлешен оештыру. | 27.05-31.05 | Сарман һәм Мөслим районнары буенча хәрби комиссариат идарәсе (килешү буеча) |